СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 февраля 2017 г. г.Мензелинск № 3

**Об отчете главы Верхнетакерменского сельского поселения Мензелинского муниципального района Республики Татарстан**

Заслушав и обсудив доклад главы Верхнетакерменского сельского поселения Мензелинского муниципального района Республики Татарстан «Об итогах социально-экономического развития Верхнетакерменского сельского поселения Мензелинского муниципального района РТ за 2016 год и задачах на 2017 год», Совет Мензелинского муниципального района РЕШИЛ:

1. Отчет главы Верхнетакерменского сельского поселения Мензелинского муниципального района Республики Татарстан «Об итогах социально-экономического развития Верхнетакерменского сельского поселения Мензелинского муниципального района РТ за 2016 год и задачах на 2017 год» утвердить и довести до сведения населения района.

2. Аппарату Совета Мензелинского муниципального района обобщить предложения и замечания, высказанные в ходе сессии.

3. Поручить Исполнительному комитету разработать и внести на рассмотрение Совета Мензелинского муниципального района план мероприятий по реализации замечаний и предложений.

4. Контроль за исполнением настоящего решения возложить на заместителя главы района Назмиева К.Р. и постоянные комиссии Совета муниципального района.

Глава, Председатель Совета
Мензелинского
муниципального района - А.Ф.Салахов

Хәерле көн хөрмәтле Фәрид Хәйруллович,

хөрмәтле президиум, депутатлар, чакырылган кунаклар!

Бүгенге яшәешебез республикада кызу темплар белән баручы яңалыклар, яхшы үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнгән.

Халык телендә "Олы өйдә нәрсә булса, кече өйгә шул кирәк" дигән әйтем бар. Чыннан да, республикабыз масштабында нинди эшләр башкарылса, аның кече берәмлекләрендә, авыл җирлекләрендә дә эшчәнлегебезне шул үрнәктә оештырырга тырышабыз. Үзебезнең "кече өебездә" җирлекнең уңышлы үсешен тәэмин итү өчен нәтиҗәле эш алып барабыз.

Бүген моның өчен Югары Тәкермән авыл җирлегендә бар мөмкинлекләр дә тудырылган.

Республикабыз, район җитәкчеләренең үз хуҗалыгында мал асраучы гади халык турында ныклы кайгыртучанлык күрсәтү билгесе булып, авылыбызда ветеринария пункты, Авыл клублары Программасы кысалаларында 300 урынлы клуб, мәктәп янында балалар өчен спорт мәйданчыгы, авылларны төзекләндерүгә Республикабыз биргән 1млн.грантка су линиясен алыштыру, яшьләр өчен төзелгән йортлар, урамнарны яктырту, юлларны төзекләндерү кебек күркәм яңалыклар – әлеге программалар нәтиҗәсе.

Авылдагы проблемаларны хәл итүдә зур ярдәм – Республикабызда әйдәп баручы үзара салым программасы дип уйлыйм.

2015 нче елда җыелган үзара салымның иң күп өлеше Түбән Тәкермән авылында урамнарны яктыртуга тотылды, бер өлешенә яу кырында батырларча һәлак булган авылдашларыбыз истәлегенә һәйкәл куелды, һәйкәлгә бара торган юлга брусчатка түшәлде, ике авыл зират территориясенә контейнер мәйданчыклары һәм контейнерлар урнаштырылды.

Агымдагы елда бу средстволарны авыл урамнарын төзекләндерүгә тоттык.

**Авыл эчендәге юлларны үзебезнен көч белән төзекләндерәбез. Ә менә ике авыл арасына асфальт юл түшәү (озынлыгы 2,5 км) әлегә хәл ителә алмый торган проблемаларыбызнын берсе. Югары һәм Түбән Тәкермән авыллары арасындагы юлны салуда Республика ярдәменә бик өметләнәбез.**

Эш яшендәге кешеләрне, эш урыннары белән тәэмин итү, яшәү шартларын яхшырту – төп бурычларыбызның берсе дип саныйбыз. Югары Тәкермән авыл җирлегендә эшләүче "Чулман" хуҗалыгында 60ка якын кеше хезмәт куя.

Без районыбыз башлыгы Айдар Фаслаховичның "Тормыш җитештерүләр һәм реаль эшләр булган жирдә генә гөрли" дигән сүзләренә таянып, хужалык житәкчеләре белән бергә һәм бердәм булып, ярдәмләшеп яшибез. Аларга төрле мәшакәтьләр белән мөрәҗәгать итәбез (урамнарны кардан чистарту, чүп үләннәрен чабу,төрле чаралар уздырганда иганәчелек ярдәме күрсәтү).Үзебез дә читтә калмыйбыз(һәр атнада өмәләрдә катнашабыз,яфрак- азык әзерләүдә булышабыз).

Фермерларыбыз безнең якын ярдәмчеләребез. Борчу мәшәкатьләре, иртәдән кичкә кадәрле хезмәте куп булса да, Татарстаннын атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, яшелчәче фермер Дәүләтовларның тату гаиләсе авыл тормышын бернәрсәгә дә алыштырырга җыенмый. Хуҗалыкның матди-техник базасы елдан ел ныгый бара.

2016 ел нәтиҗәләре буенча халыкка күрсәткән ярдәме өчен Нәсим Дәүләтов "Ел иганәчесе" исеменә лаек булды.

Җирлегебездә терлекчелек, игенчелек өлкәсендә дә фермерларыбыз тырышып хезмәт куялар.

Шәхси хуҗалыкларда 402 баш мөгезле эре терлек (шулардан 159 савым сыер), 590 баш сарык һәм кәҗә асрала. Аларга ярдәм йөзеннән, республика бюджетыннан халыкка 531000 сум субсидия таратылды.

Авыл хуҗалыгы продукциясен реализацияләү максатында авыл җирлегендә ярминкәләр оештыруны башлап җибәрдек. Авылдашларыбыз тарафыннан бу яңалык бик җылы кабул ителде, аларның һәрберсе бәйрәм төсендә үтә.

Эшчән авыл халкы районда, Яр Чаллы шәһәрендә оештырылган авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә дә актив катнаша.

**Бу нисбәттән районыбыз үзәгендә яңа таләпләргә туры китереп җиһазландырылган авыл хуҗалыгы продукциясе белән сәүдә итү урыны булдыру проблемасы тора.**

Районыбыз җитәкчелегенең авыл җирлегендә яшәргә теләгән яшь кадрларны кайгырту инициативасы күп кенә гаиләләргә сөенеч алып килде. Авыл хуҗалыгы җирләреннән 58 кишәрлекне авыл җирлеге фондына күчерүгә ирешелде. Күп балалы гаиләләр, яшь белгечләр җир һәм торак белән тәэмин ителәләр.

Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү буенча Федераль максатчан программаны тормышка ашыру кысаларында, Югары Тәкермән авылы җирлегендә бүгенге көндә су һәм электр белән тәэмин итү, территорияне төзекләндерү буенча зур эш алып барыла: газүткәргеч торбалар салынды, шулай ук су белән тәэмин итү буенча – ике насос станциясе, ике су башнясы, суүткәргеч линиясе куллануга әзер.

**Фәрид Хәйруллович, авыл җирлекләрендә су башняларын лицензияләү процедурасын финаслауның нәтиҗәле механизмын Республика дәрәҗәсендә эшләп, тормышка ашыру мөмкин булмасмы икән?**

Төрле программаларда катнашып, соңгы елларда гына авыл жирлегендә 37 йорт сафка бастырылды.

Безгә шәһәрдән кайтырга теләк белдерүче яшь белгечләр бар, ләкин аларны торыр урыны булмау борчый.

**Бүгенге көндә авыл җирендә эшләүче яшьләр өчен «Арендага торак» программасын тормышка ашыру иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора.**

Россия Федерациясы Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан депутатлыкка кандидатлар белән очрашу вакытында Тәкермән халкы исеменнән без яна модульле фельдшер-акушерлык пунктының бик кирәклеге турында сорау күтәрдек. Республика программасы кысаларында агымдагы елда авыл халкын сөендереп Югары Тәкермән авылында фельдшер-акушерлык пункты төзеләчәк.

Бу зур ярдәмнәрегез, изге эшләрегез өчен, Президентыбыз Рөстәм Нургалиевичка, Дәүләт Советында авыл халкының көндәлек мәшәкатьләрен аңлап, карарлар кабул иткәнегез өчен Сезгә, Фәрид Хәйруллович, барлык авылдашларым, район халкы исеменнән чын йөрәктән зур рәхмәтләребезне җиткерәм.

Үз тарихын белеп, гореф-гадәтләрен хөрмәт итеп яшәгән халыкның киләчәге бар. Бөек шагыйрә, мәшһүр авылдашыбыз Гөлшат Зәйнашеванын исемен мәңгеләштерү йөзеннән гаять күп эшләр эшләнә.

Иганәчеләребез ярдәме белән авылга керү юлында стела ачтык. Г.Зәйнашева исемендәге яңа урамда яшьләр өчен йортлар салына башлады. 5 нче ел рәттән Сара Садыйкова исемендәге җәмәгать фонды, авылдашлар, райондашлар катнашында “Кояш гомере телим мин, Минзәләм, сина!” фестивале уздырыла.

Авылдашларыбыз Г.Зәйнашева, Марс Шабаев, Г.Сабитов исемнәрен мәңгеләштерү максатында һәм яуда калган авылдашлар истәлегенә Хәтер һәм ял бакчасы булдыру, аны Гөлбакча исеме белән рәсмиләштерү планы белән яшибез.

Чыгышымны авылыбызнын сайрар былбылы Гөлшат апа Зәйнашеваның шигырь юллары белән тәмамлыйм:

Авыл исән чакта җырлар исән,
Гармуннарның әле бар моңы.
Чын татарча җырлап, гармун уйнап
Яшә, моңлы татар авылы!

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!